КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 22 декабрь г.Казань № 1121

Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим урнаштыру турында

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чараларын уздыру чорында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, гражданнарның сәламәтлеген һәм гомерен, физик һәм юридик затларның мөлкәтен, янгыннардан дәүләт яисә муниципаль мөлкәтне яклау максатларында, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 25 декабреннән 2026 елның 11 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим урнаштырырга.

2. Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда 3 класслы куркыныч пиротехника әйберләрен түбәндәге чикләрдә урнашкан территорияләрдә файдалануны тыю билгеләргә:

сәнәгать, транспорт инфраструктурасы объектлары (автомобиль юлларыннан тыш), ягулык-энергетика комплексы чикләреннән 500 метр;

торак-коммуналь хуҗалык, авыл хуҗалыгы объектлары чикләреннән, кешеләр күп була торган объектлар, автомобиль юллары, шәхси йорт хуҗалыклары чикләреннән 30 метр;

күпфатирлы торак йортлардан 30 метр.

3. Бу карарга теркәлгән янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда 30 һәм 500 метрлы зоналарда пиротехника әйберләрен куллану тыелган объектлар исемлеген расларга.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына әлеге карар белән расланган исемлеккә кертелмәгән янгынга каршы махсус режим

гамәлдә булган чорда 30 һәм 500 метрлы зоналарда пиротехника әйберләрен файдалану тыелган өстәмә объектларны билгеләүне тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

ведомство буйсынуындагы оешмаларда Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чараларын әзерләү һәм уздыру чорында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары комплексын гамәлгә ашырырга;

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чараларын уздыру урыннары турында хәбәр итәргә;

янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чараларын уздыру өчен җаваплы вазыйфаи затларны укытуны оештырырга;

ведомство буйсынуындагы объектларда Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чараларын уздыру чорында кизү персонал санын арттырырга;

ведомство буйсынуындагы оешмаларның ябык биналарында (махсус сцена эффектларыннан тыш) утлы эффектлы пиротехника әйберләрен саклауны һәм куллануны булдырмаска.

6. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

2025 елның 15 декабренә кадәр Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм көннәрендә янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәү буенча белешмәлек эшләргә;

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм көннәрендә янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлеше турында халыкка мәгълүмат бирүне оештырырга.

7. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

балалар Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чараларын үткәрү урыннарын исәпкә алырга, чарада катнаша торган объектларда законнар кысаларында күзәтчелек һәм профилактика чаралары комплексын үткәрүне;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре белән берлектә, моның өчен билгеләнмәгән сәүдә урыннарында пиротехника әйберләрен сатуны ачыклау һәм чикләү буенча территорияләргә барып тикшерүләр үткәрүне оештырырга һәм уздырырга.

8. Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

пиротехника әйберләрен сатканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы

өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын тайпылышсыз үтәүне тәэмин итүне;

әлеге карарның нигезләмәләрен, шулай ук пиротехника әйберләрен таратканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү өлешендә халык, юридик затлар, шул исәптән пиротехника әйберләрен ваклап сатуны гамәлгә ашыручы затлар арасында аңлату эшләре уздыруны оештыруны;

2025 елның 15 декабренә кадәр гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү комиссияләре утырышларында һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чараларын уздыру урыннарының янгын куркынычсызлыгы мәсьәләләрен карап тикшерүне;

ирекле һәм муниципаль янгын сагы әгъзаларының янгын сүндерү техникасы белән тәүлек буе кизү торуын оештыру буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыруны;

оператив хезмәтләрне һәм оешмаларны Яңа ел бәйрәм чараларына һәм түбән температуралар чорына әзерләү мәсьәләләре буенча фикер алышуны;

тышкы янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу өчен шартлар тудыру буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыруны, шул исәптән төзек булмаган су чыганакларын ремонтлауны оештыруны, елның кышкы вакытында су җыю башняларын, туңмый торган тишекләрдән табигый сулыклар белән су алу, су чыганакларына кардан су юлларын чистарту җайланмалары белән җиһазлауны;

шәхси автотранспортны турыдан-туры янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларында машина кую мөмкинлеге булмау турында халыкка хәбәр итәргә, кирәк булганда, су чыганакларына янгын сүндерү машиналарын кертүне кыенлаштыра торган автотранспортны эвакуацияләүне оештыруны;

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә караган күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эше идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш буенча территориаль бүлекләре (бүлекчәләре) һәм Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе белән килештереп, пиротехника әйберләрен сату урыннарында куркынычсызлык тәэмин итү буенча чаралар күрүне;

пиротехник әйберләрне саклау һәм сату шартларын мониторинглау комиссияләрен төзүне;

урам чыршыларын бизәү сыйфатында сертификацияләнгән электр гирляндаларын файдалануны;

пиротехника әйберләрен кулланганда куркынычсызлык таләпләрен үтәү чаралары турында халыкка мәгълүмат бирү буенча эш оештыруны;

янгыннар белән хәл катлауланган очракта, тиешле территорияләрдә пиротехника әйберләре куллануны тыю билгеләүне;

2025 елның 25 декабренә кадәр һәр торак пунктта пиротехника әйберләре куллану урыннарын билгеләүне, «Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 2010 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләрен үтәүне тикшереп торырга һәм бу хакта халыкка хәбәр итүне;

2025 елның 29 декабреннән 2025 елның 11 гыйнварына кадәр торак йортларда гражданнар белән янгын куркынычсызлыгы чаралары турында профилактик әңгәмәләр үткәрүне, шул ук вакытта күпбалалы, имин булмаган гаиләләр, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнар яшәгән урыннарга аерым игътибар биреп, оештыру максатында Янгынга каршы дәүләт хезмәте хезмәткәрләре, ирекле янгын сагы әгъзалары, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча территориаль бүлекчәләре һәм полиция хезмәткәрләре (килешү буенча), җирле үзидарә органнары, муниципаль районнар (шәһәрләр) башкарма комитетларының административ-техник комиссияләре, халыкны социаль яклау идарәләре (бүлекләре) хезмәткәрләре арасыннан профилактик төркемнәр төзүне.

9. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

пиротехника әйберләрен җитештерү, саклау һәм сату эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга пиротехника әйберләрен сатканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге Россия Федерациясе законнарын тайпылышсыз үтәүне тәэмин итүне;

автозаправка станцияләре һәм комплексларын эксплуатацияләүче юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга электр гирляндаларын һәм таләп ителә торган шартлау саклау дәрәҗәсе булмаган башка иллюминацияне, территорияләрне һәм югарыда күрсәтелгән объектларның биналарын бизәгәндә куллануны төшереп калдыруны;

Татарстан Республикасы территориясендә күпләп һәм ваклап сату белән шөгыльләнүче оешмалар җитәкчеләренә законнарда билгеләнгән тиешле сертификатлары (ярашлылык турында декларацияләре) булмаган пиротехника әйберләрен һәм электр гирляндаларын, шулай ук техник документациясендә янгын куркынычы күрсәткечләре һәм алар белән эш иткәндә янгын куркынычсызлыгы чаралары күрсәтелмәгән Яңа ел бизәү әйберләрен, ясалма чыршыларны сатуны рөхсәт итмәү буенча чаралар күрүне;

янгынга каршы тышкы су белән тәэмин итү чыганаклары балансында булган оешмалар җитәкчеләренә аларны төзек хәлдә тотуга юнәлдерелгән чаралар күрергә, шул исәптән янгын сүндерү машиналарын су чыганакларына кертүне тәэмин итәргә, шулай ук су чыганакларын кар һәм боздан вакытында чистартырга;

гражданнарга дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына «112», «01», «02» ашыгыч оператив хезмәтләре телефоннары буенча, шулай ук мөмкин булган башка ысуллар буенча пиротехника әйберләрен рөхсәтсез куллану очраклары турында мәгълүмат бирергә.

10. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм көннәрендә янгын куркынычсызлыгы таләпләре үтәлеше турында халыкка мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

11. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында» 2024 ел, 29 ноябрь, 1082 нче;

«Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында» 2025 ел, 10 апрель, 212 нче.

12. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин